**Арча муниципаль районыТүбән Аты төп гомуми белем мәктәбе каршында эшләп килүче “Хыял” иҗат төркеменең эшчәнлегенә иҗади отчёт.**

«Хыял» дип исемләнгән иҗат группасы үзенең эшчәнлеген 2018 нче елда 6 нчы сыйныф укучылары белән башлап җибәрде.Сыйныфтагы 4 малай һәм 4 кыз Г.Камалның “Беренче театр” әсәрен сәхнәләштерделәр.Спектакль башта мәктәп сәхнәсендә,аннары Мәдәният йорты сәхнәсендә күрсәтелде.Укучыларга костюмнар әзерләүдә,декорация корганда татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәмидуллина З.Я., сыйныф җитәкчесе Маликова Г.Г. ,барлык укытучылар ярдәм күрсәттеләр.

Иҗат белән рухланган балалар тәкъдиме белән Р.Батулланың “Кичер мине,әнкәй!” әсәрен сәхнәләштерү эшенә алындылар.

Шулай ук “Өч кыз” дип исемләнгән татар халык әкиятен,Р.Мөхәммәтшаның “Өрә белмәгән көчек” әсәрләре дә төрле бәйрәм чараларында уңышлы гына куелды.

“Хыял” төркеменә йөрүче егетләр,кызлар 9 нчы сыйныфка җиттеләр инде.Әлеге төркемнең иҗат юлына күз салсак,шактый уңышларын да күрергә мөмкин.2020-2021 нче,2021-2022 нче уку елларында үткәрелгән районкүләм балалар һәм яшүсмерләр театр фестивалендә 3 нче урын алып, Мактау кәгазенә лаек булдылар.

2019 нгчы елда “Сәхнә” журналы тарафыннан үткәрелгән “Сәйәр” онлайн-бәйгесендә катнашып,призлы урын яуладылар.

Республикакүләм «Милли мультFest» кинофестивалендә “Заманча Кәҗә белән Сарык” әсәре өчен иҗат коллективы “Балалар фольклоры” дигән махсус номинациядә җиңүче дип табылды,диплом белән бүләкләнде.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы: З.Я.Хәмидуллина.